**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Порядок предоставления гарантий судьям Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающим в отставке

1. Внести в Порядок предоставления гарантий судьям Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающим в отставке, утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 30 ноября 2022 года № УП-842 «Об утверждении Порядка предоставления гарантий судьям Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающим в отставке», следующие изменения:

а) пункт 7 изложить в следующей редакции:

«7. Размер ежемесячного пожизненного содержания судьи Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающего в отставке, увеличивается (индексируется) путем умножения размера ежемесячного пожизненного содержания судьи Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающего в отставке, на коэффициент увеличения (индексации) размеров должностных окладов судей федеральных судов общей юрисдикции, установленный актом Президента Российской Федерации. При этом в расчете применяется размер ежемесячного пожизненного содержания судьи Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающего в отставке, с учетом ранее произведенных индексаций.

Увеличение (индексация) размера ежемесячного пожизненного содержания судьи Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающего в отставке, предусмотренное настоящим пунктом, осуществляется уполномоченным органом в срок, установленный соответствующим актом Президента Российской Федерации об увеличении (индексации) размеров должностных окладов судей федеральных судов общей юрисдикции.

Также уполномоченным органом производится пересчет размеров ежемесячного пожизненного содержания судей Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающих в отставке, в случае увеличения (индексации) размеров любых составляющих ежемесячного денежного вознаграждения судей федеральных судов общей юрисдикции.»;

б) пункт 11 изложить в следующей редакции:

«11. Судье Конституционного суда Республики Татарстан, пребывающему в отставке, получающему ежемесячное пожизненное содержание из бюджета Республики Татарстан, по его заявлению, представляемому в уполномоченный

орган, один раз в год за счет средств бюджета Республики Татарстан производится компенсация затрат на санаторно-курортное лечение и проезд к месту прохождения санаторно-курортного лечения и обратно, при условии предоставления им подтверждающих документов о прохождении санаторно-курортного лечения в Российской Федерации и проездных документов к месту лечения и обратно, в размере не более 30 процентов ежемесячного пожизненного содержания. Порядок компенсации затрат на санаторно-курортное лечение и проезд к месту прохождения санаторно-курортного лечения и обратно утверждается уполномоченным органом.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
08 мая 2024 года
№ 326

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларына гарантияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларына гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 30 ноябрендәге ПУ-842 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларына гарантияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына гомерлек айлык акчалата түләү күләме Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясының гомерлек айлык акчалата түләү күләмен Россия Федерациясе Президенты актында билгеләнгән федераль гомуми юрисдикция судлары судьяларының вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру (индексацияләү) коэффициентына тапкырлау юлы белән арттырыла (индексацияләнә). Шул ук вакытта исәпләү алып барганда Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларының элек индексацияләнгән гомерлек айлык акчалата түләү күләме алына.

Әлеге пунктта каралган Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына гомерлек айлык акчалата түләү күләмен арттыру (индексацияләү) вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Президентының федераль гомуми юрисдикция судлары судьяларының вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру (индексацияләү) турында тиешле актында билгеләнгән срокта башкарыла.

Шулай ук вәкаләтле орган тарафыннан федераль гомуми юрисдикция судлары судьяларының айлык акчалата түләвенең теләсә кайсы өлеше арттырылган (индексацияләнгән) очракта, Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларының гомерлек айлык акчалата түләү күләмнәре яңадан исәпләнелә.»;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы бюджетыннан гомерлек айлык акчалата түләү алучы отставкадагы судьясына аның вәкаләтле органга биргән гаризасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан елына бер тапкыр шифаханәләрдә, ял йортларында дәвалану һәм шифаханәдә, ял йортында

дәвалану урынына транспортта бару һәм кайту чыгымнары, аның тарафыннан Россия Федерациясендәге шифаханәдә, ял йортында дәвалануын раслый торган документлар һәм дәвалану урынына транспортта бару һәм кайту документлары бирелү шарты үтәлгәндә, гомерлек айлык акчалата түләүнең 30 процентыннан артык булмаган күләмдә компенсацияләнә. Шифаханәдә, ял йортында дәвалану һәм шифаханәдә, ял йортында дәвалану урынына транспортта бару һәм кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибе вәкаләтле орган тарафыннан раслана.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 08 май
№ 326